СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д.53,
с. Ерыклы,423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы,423185

тел.,факс.:(8-84348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

Зирекле авыл җирлеге советы утырышы
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
КАРАРЫ

2021 елның 29 гыйнваре № 7-17

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2012 елның 23 ноябрендәге 17-46 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2012 елның 23 ноябрендәге 17-46 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» нә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 30 статьяның 1.2 пункты җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән файдалануның иң чик параметрларын яңа редакциядә укырга:

- торак төзелеше өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 1000 кв. м; максималь 2500 кв. м. (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый)

- бакчачылык өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 400 кв. м; максималь 2000 кв. м; (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый)

- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 1000 кв. м; бер үк вакытта милек хокукында һәм (яки) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарның башка хокукында булырга мөмкин булган җир кишәрлекләренең гомуми мәйданының максималь күләме ике гектарга, шул исәптән торак пункт чикләрендә бер гектарга тиң (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый)

- 30 статьяның 4.2 пункты җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын файдалану рөхсәт ителгәннең иң чик күләмнәрен участок күләмен яңа редакциядә укырга:

- торак төзелеше өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 1000 кв. м; максималь 2500 кв. м. (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый)

- блокланган торак төзелеше өчен җир кишәрлегенең минималь мәйданы 1000 кв. м; максималь 2500 кв. м. (элек бирелгән җир кишәрлекләренә кагылмый)

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2017 елның 23 гыйнваре 29-44 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен раслау турында «2012 елның 23 ноябрендәге 17-46 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының Законлылык, табигатьне саклау, җирдән файдалану һәм территорияне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Зирекле авыл җирлеге башлыгы Җ.Г.Гәйфетдинов

Республика Татарстан муниципальное образование «Зиреклинское сельское поселение» Новошешминского муниципального района
р 05-12002/14
СОВЕТ
ЗИРЕКЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ